Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XLV-11**

Балык Бистәсе штп. 2019 елның 24 сентябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2010 елның 15 октябрендәге I-4 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитет җитәкчесе вазифасын алмаштыруга конкурс үткәрү тәртибе турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актны законнар белән тәңгәллеккә китерү максатларында, 2019 елның 1 апрелендәге ""Мәҗбүри пенсия иминиятләве системасында индивидуаль (персонификацияләнгән) исәп турында" Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 48-ФЗ номерлы Федераль закон, 2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 131-ФЗ номерлы Федераль законның 37 маддәсе, 2007 елның 2 мартындагы "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 25-ФЗ номерлы Федераль законның 16 маддәсе, Татарстан Республикасының Муниципаль хезмәт турында Кодексының 8, 19 маддәләре, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 45-ТРЗ номерлы Законының 26 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 30, 48 маддәләре нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2010 елның 15 октябрендәге I-4 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитет җитәкчесе вазифасын алмаштыруга конкурс үткәрү тәртибе турында Нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2013 елның 22 июлендәге XXVII-3 номерлы карары, 2014 елның 13 декабрендәге XLII-5 номерлы карары, 2018 елның 4 сентябрендәге XXXIII-10 номерлы карары, 2019 елның 1 апрелендәге XLI -6 номерлы карары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) 12 пунктның 5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5) индивидуаль (персонификацияләнгән) исәп системасында теркәлүне раслаучы документның күчермәсе;".

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм

http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3.Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының законлылык, хокук саклау, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы И.Р. Таҗетдинов